**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 8 апрелендәге 1112 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 сентябрендәге 4124 номерлы карары белән расланган Аккош күле тирәсендәге территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына таянып, **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 сентябрендәге 4124 номерлы карары белән расланган Аккош күле тирәсендәге территорияне планлаштыру проектына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 8 апрелендәге
1112 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 сентябрендәге 4124 номерлы карары белән расланган Аккош күле тирәсендәге территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырыла торган зоналар чикләре күрсәтелгән (1 нче этап) планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең 1 номерлы кушымтасы нигезендә бирергә.

2. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырыла торган зоналар чикләре күрсәтелгән (2 нче этап) планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә бирергә.

3. Территорияне планлаштырып үстерү характеристикалары турындагы Нигезләмәнең 3.2 пунктында:

3.1. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- урам-юл челтәре объектларын урнаштыру зонасы»;

3.2. Түбәндәге эчтәлекле «Территориядә төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, капиталь төзелеш объектлары характеристикалары*» таблицасын өстәргә:

| | **«Зона төре** | **Зона мәйданы, га** | **Рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары** | **Объектларның билгеләнеше** | **Капиталь төзелеш объектларының максималь катлар саны** | **Торак фондының (фатирларның) максималь гомуми мәйданы, мең кв.м** | **Торак фондының (фатирларның) максималь тыгызлыгы, мең кв. м/га** | **Торак булмаган билгеләнештәге биналарның гомуми мәйданы, мең кв.м** | **Урнаштырыла торган объектлар турында белешмәләр** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шәхси һәм блоклап төзелгән торак | 0,56 | 2.1; 3.1.1 | Билгеләнмәгән | 3 | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | 0 | Шәхси торак төзелеше |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | йортлар урнаштыру зонасы | | | | | | | | |
| 2 | Ял һәм туризм, сәламәтләндерү лагерьларын урнашты-ру зонасы | 12,00 | 3.1.1; 3.3; 3.4.1; 3.4.2; 3.6.1; 3.6.2; 4.1; 4.6; 4.8.1; 5.1.2; 5.1.3; 5.1.7; 5.2; 5.2.1; 7.4; 9.2; 9.2.1 | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Саклап калу планлаштырыла торган балаларны сәламәтләндерү лагере (гамәлдәге) (капиталь ремонт/реконструкция/төзелеш таләп итә) |
| 3 | Ял һәм туризм, сәламәтләндерү лагерьла-рын урнашты-ру зонасы | 1,93 | 3.1.1; 3.3; 3.4.1; 3.4.2; 3.6.1; 3.6.2; 4.1; 4.6; 4.8.1; 5.1.2; 5.1.3; 5.1.7; 5.2; 5.2.1; 7.4; 9.2; 9.2.1 | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Саклап калу планлаштырыла торган сәламәтләндерү спорт лагере (гамәлдәге) (капиталь ремонт/реконструкция/төзелеш таләп итә) |
| 4 | Урам-юл челтәре объектла-рын урнашты-ру зонасы | 0,49 | 3.1.1; 12.0.1 | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Урам-юл челтәре |

*Характеристиклар 2 нче этап өчен китерелгән»


3.3. түбәндәге эчтәлекле «Территорияне файдалану балансы*» таблицасын өстәргә:

| «№ т/б | Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары төре | Мәйданы, га | Мәйдан өлеше, % |
|---|---|---|---|
| 1 | Шәхси һәм блоклы торак төзелеше | 0,56 | 3,74 |
| 2 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 13,93 | 92,99 |
| 3 | Урам-юл челтәре объектларын урнаштыру | 0,49 | 3,27 |
| Барлыгы | | 14,98 | 100 |

*Характеристиклар 2 нче этап өчен китерелгән»

---

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 сентябрендәге 4124 номерлы карары белән расланган Аккош күле тирәсендәге территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта



Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 сентябрендәге 4124 номерлы карары белән расланган Аккош күле тирәсендәге территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта

